Әлки муниципаль районы Советы

Татарстан Республикасы

**КАРАРЫ**

№188 2018 нче елның 27 нче сентябреннән

Әлки муниципаль районында муниципаль
вазыйфаларны биләүче затларга һәм
муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар
эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле бүләкләү
тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 197 номерлы карары һәм Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле бүләкләү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге 149 номерлы «Әлки муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында http://alkeevskiy.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы башлыгы,
Әлки муниципаль районы Совет рәисе Никошин А.Ф.

2018 елның 27 сентябре
188 № Әлки муниципаль
районы Советы карарына
Кушымта.

Әлки муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы Нигезләмә.

1. Әлеге Нигезләмә Әлки муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле бер тапкыр бирелә торган бүләкләү (алга таба - бер тапкыр бирелә торган бүләкләү) тәртибе турында Татарстан Республикасы Кодексының 31 статьясы, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде.

2. Муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм муниципаль хезмәткәр хезмәттән (алга таба - муниципаль хезмәт) азат ителгәндә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, муниципаль хезмәт хезмәт стажы 15 ел булганда, айлык хезмәт хакының бишләтә күләме дәрәҗәсендә һәм муниципаль хезмәтнең алдагы һәр тулы елы өчен ( 10нан артмаска тиеш) өстәмә рәвештә 0,5 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түләнә. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итү көненнән билгеләнә.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч, муниципаль хезмәттән эштән азат ителү яки "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләү, муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле эштән азат ителүдән тыш һәм тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясен алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда аңлашыла.

3. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү турындагы карар җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә, Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы (алга таба - җирле үзидарә органы) тарафыннан тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү турындагы карар кабул ителү белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

4. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгәнче хезмәт иткән җирле үзидарә органы тарафыннан (эшнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча) түләнә.

5. Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләү өчен «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль бюджет учреждениесе түбәндәге документларны тәкъдим итә:

муниципаль хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы турында белешмә;

житәкче һәм кадрлар хезмәте тарафыннан расланган муниципаль хезмәттә эшләү стажы турында белешмә;

кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билетының күчермәләре;

класслы чин бирү, муниципаль хезмәткәрне айлык хезмәт хакы составына керүче вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү турында приказлардан өземтә;

муниципаль хезмәткәрнең эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.

6. Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органы әлеге карарның 5 пункты нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү көненә кадәр 30 календарь көн кала документлар тапшыра.

7. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләгәндә айлык вазыйфаи оклад, класс чиннары өчен оклад һәм муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен бирелгән өстәмәләр исәпкә алына.

8. "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ документлар тапшырганнан соң 20 көн эчендә җирле үзидарә органына муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү өчен бюджет ассигнованиеләре турында һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәрнамәләрне җиткерә яисә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү өчен җирле үзидарә органына акча бирүдән нигезле баш тарта.

"Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ әлеге карарның 5 пунктында каралган барлык документлар да күрсәтелмәгән очракларда җирле үзидарә органына бер тапкыр бирелә торган бүләкләү өчен акча бирүдән баш тарта.

9. Җирле үзидарә органы әлеге хәбәрнамәләр нигезендә муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне башкара.

10. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү хезмәт кенәгәсендәтамга салып түләнә. Граждан тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыкканнан соң муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аннан соң муниципаль хезмәтне туктатканда бер тапкыр бирелә торган бүләк кабат түләнми.

11. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү Әлки муниципаль районы бюджетыннан әлеге карар нигезендә башкарыла.